# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 21 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Мәгариф турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, № 2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 19 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$. Дәүләт гражданнарга дәүләткә карамаган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә, шулай ук дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуда ярдәм итүне Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативлары нигезендә тиешле федераль дәүләт мәгариф стандартлары һәм (яисә) федераль дәүләт таләпләре чикләрендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетларыннан кирәкле күләмдә бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән башкара.";

2) 29 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пунктча өстәргә:

“11$^{1}$) дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә гражданнарның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуын Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф учреждениеләренең һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренең уку-укыту эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү нормативлары нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны, дәреслекләргә һәм уку-укыту әсбапларына, укыту-күрсәтмә әсбапларга, укытуның техник чараларына, уеннарга, уенчыкларга, кирәк-ярак әйберләргә чыгымнарны финанслау өлешендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә финанс белән тәэмин итү;”;

3) 30 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2$^{1}$ пунктча өстәргә:

“2$^{1}$) дәүләткә карамаган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларның белем алуын муниципаль мәгариф учреждениеләре өчен билгеләнгән нормативлар нигезендә педагогик хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны, укыту-күрсәтмә әсбапларга, укытуның техник чараларына, уеннарга, уенчыкларга, кирәк-ярак әйберләргә чыгымнарны финанслау өлешендә мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле күләмдә финанс белән тәэмин итү;”;

4) 37 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4. Дәүләт аккредитациясе булган дәүләткә карамаган гомуми белем бирү учреждениеләрендә гражданнарның мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми белем алуын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”;

5) 47 статьяның 5 пунктында “балаларын карап тоту өчен” сүзләреннән соң “(балаларын карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә;

6) 47$^{1}$ статьяда:

а) статьяның исемендә “баланы карап тоту өчен” сүзләреннән соң “(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта “баланы карап тоту өчен” сүзләреннән соң “(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта:

“баланы карап тоту өчен” сүзләреннән соң “(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә, “баланы карап тотуга” сүзләреннән соң “(баланы карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә;

“чикләнгән балаларны” сүзләрен “чикләнгән балаларны карап тоту өчен (балаларны карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләренә алмаштырырга;

“балаларны карап тоту өчен” сүзләреннән соң “(балаларны карап тору һәм тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә;

г) 3 пунктта “баланы  карап тоту  өчен” сүзләреннән соң “(баланы карап тору һәм  тәрбиядә тоту өчен)” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 9 июле
№ 43-ТРЗ